**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**О внесении изменений в Указ Президента Республики Татарстан «Об утверждении Положения об Управлении Президента Республики Татарстан по вопросам антикоррупционной политики»**

В связи с изданием Указа Президента Российской Федерации от 15 июля 2015 года № 364 «О мерах по совершенствованию организации деятельности в области противодействия коррупции» и в целях совершенствования организации деятельности в области противодействия коррупции в Республике Татарстан **постановляю**:

1. Внести в Указ Президента Республики Татарстан от 31 января 2011 года № УП-37 «Об утверждении Положения об Управлении Президента Республики Татарстан по вопросам антикоррупционной политики» (с изменениями, внесенными указами Президента Республики Татарстан от 26 июля 2013 года № УП-693, от 3 декабря 2013 года № УП-1176 и от 20 августа 2014 года № УП-797) следующие изменения:

а) преамбулу изложить в следующей редакции:

«В связи с изданием Указа Президента Российской Федерации от 15 июля 2015 года № 364 «О мерах по совершенствованию организации деятельности в области противодействия коррупции», в соответствии с указами Президента Республики Татарстан от 20 марта 2006 года № УП-114 «Об утверждении Положения об Аппарате Президента Республики Татарстан» и от 5 апреля 2006 года № УП-134 «Об Аппарате Президента Республики Татарстан» **постановляю:**»;

б) Положение об Управлении Президента Республики Татарстан по вопросам антикоррупционной политики изложить в новой редакции согласно приложению;

в) дополнить пунктом $1^1$ следующего содержания:

«$1^1$. Возложить на Управление Президента Республики Татарстан по вопросам антикоррупционной политики функции органа Республики Татарстан по профилактике коррупционных и иных правонарушений.».

2. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Президент**
**Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ОБЩИЙ ОТДЕЛ ГОМУМИ БҮЛЕК ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ

Казань,Кремль
13 октября 2015 года
№ УП-987

Приложение
к Указу Президента
Республики Татарстан

от «13» октября 2015 года

№ УП - 987

**Положение**
**об Управлении Президента Республики Татарстан**
**по вопросам антикоррупционной политики**

I. Общие положения

1. Настоящим Положением определяются правовое положение, основные задачи и функции Управления Президента Республики Татарстан по вопросам антикоррупционной политики (далее - Управление).

2. Управление является структурным подразделением Аппарата Президента Республики Татарстан, образованным в целях обеспечения осуществления Президентом Республики Татарстан полномочий по организации антикоррупционной деятельности.

Управление осуществляет функции органа Республики Татарстан по профилактике коррупционных и иных правонарушений.

3. Управление в своей деятельности руководствуется Конституцией Российской Федерации, федеральными конституционными законами, федеральными законами, указами и распоряжениями Президента Республики Татарстан, постановлениями и распоряжениями Правительства Российской Федерации и иными нормативными правовыми актами Российской Федерации, Конституцией Республики Татарстан, Законом Республики Татарстан от 4 мая 2006 года № 34-ЗРТ «О противодействии коррупции в Республике Татарстан», иными законами Республики Татарстан, указами и распоряжениями Президента Республики Татарстан, иными нормативными правовыми актами Республики Татарстан, решениями Совета при Президенте Российской Федерации по противодействию коррупции и его президиума, принятыми в пределах их компетенции, а также настоящим Положением.

II. Основные задачи Управления

4. Основными задачами Управления являются:

а) обеспечение реализации Президентом Республики Татарстан полномочий в области антикоррупционной политики;

б) осуществление функций специального государственного органа по реализации антикоррупционной политики Республики Татарстан, предусмотренного Законом Республики Татарстан от 4 мая 2006 года № 34-ЗРТ «О противодействии коррупции в Республике Татарстан»;

в) профилактика коррупционных правонарушений в государственных органах Республики Татарстан, организациях, созданных для выполнения задач, поставленных перед государственными органами Республики Татарстан.

## III. Основные функции Управления

5. Управление осуществляет следующие основные функции:

а) обеспечение соблюдения лицами, замещающими государственные должности Республики Татарстан, для которых федеральными законами или законами Республики Татарстан не предусмотрено иное (далее – лица, замещающие государственные должности Республики Татарстан), и государственными гражданскими служащими Республики Татарстан запретов, ограничений и требований, установленных в целях противодействия коррупции;

б) принятие мер по выявлению и устранению причин и условий, способствующих совершению коррупционных правонарушений, а также возникновению конфликта интересов при осуществлении полномочий лицами, замещающими государственные должности Республики Татарстан, и при исполнении должностных обязанностей государственными гражданскими служащими Республики Татарстан;

в) обеспечение деятельности Комиссии по координации работы по противодействию коррупции в Республике Татарстан, подготовка материалов к заседаниям комиссии и контроль за исполнением принятых ею решений;

г) участие в пределах своей компетенции в работе комиссий по соблюдению требований к служебному поведению и урегулированию конфликта интересов, образованных в Аппарате Президента Республики Татарстан, органах исполнительной власти Республики Татарстан и органах местного самоуправления в Республике Татарстан (далее – органы местного самоуправления);

д) оказание лицам, замещающим государственные должности Республики Татарстан, государственным гражданским служащим Республики Татарстан, муниципальным служащим в Республике Татарстан и гражданам консультативной помощи по вопросам, связанным с применением законодательства Российской Федерации и Республики Татарстан о противодействии коррупции, а также с подготовкой сообщений о фактах коррупции;

е) формирование у лиц, замещающих государственные должности Республики Татарстан, государственных гражданских служащих Республики

Татарстан, муниципальных служащих в Республике Татарстан и граждан нетерпимости к коррупционному поведению;

ж) участие в пределах своей компетенции в обеспечении соблюдения в Аппарате Президента Республики Татарстан, органах исполнительной власти Республики Татарстан законных прав и интересов лица, сообщившего о ставшем ему известном факте коррупции;

з) обеспечение реализации государственными гражданскими служащими Республики Татарстан обязанности уведомлять представителя нанимателя, органы прокуратуры Российской Федерации, иные федеральные государственные органы, государственные органы Республики Татарстан обо всех случаях обращения к ним каких-либо лиц в целях склонения к совершению коррупционных правонарушений;

и) осуществление проверки:

достоверности и полноты сведений о доходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера, представленных гражданами, претендующими на замещение государственных должностей Республики Татарстан;

достоверности и полноты сведений о доходах, расходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера, представленных лицами, замещающими государственные должности Республики Татарстан;

соблюдения лицами, замещающими государственные должности Республики Татарстан, запретов, ограничений и требований, установленных в целях противодействия коррупции;

к) осуществление контроля за соблюдением законодательства Российской Федерации и Республики Татарстан о противодействии коррупции в государственных учреждениях Республики Татарстан и организациях, созданных для выполнения задач, поставленных перед органами исполнительной власти Республики Татарстан, а также за реализацией в этих учреждениях и организациях мер по профилактике коррупционных правонарушений;

л) участие в пределах своей компетенции в подготовке и рассмотрении проектов нормативных правовых актов Республики Татарстан по вопросам противодействия коррупции;

м) анализ сведений:

о доходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера, представленных гражданами, претендующими на замещение должностей государственной гражданской службы Республики Татарстан;

о доходах, расходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера, представленных государственными гражданскими служащими Республики Татарстан в соответствии с законодательством Российской Федерации и Республики Татарстан;

о соблюдении государственными гражданскими служащими Республики Татарстан запретов, ограничений и требований, установленных в целях противодействия коррупции;

о соблюдении гражданами, замещавшими должности государственной гражданской службы Республики Татарстан, назначение на которые и освобождение от которых осуществляются Президентом Республики Татарстан и Руководителем Аппарата Президента Республики Татарстан, ограничений при заключении ими после увольнения с государственной гражданской службы Республики Татарстан трудового договора и (или) гражданско-правового договора в случаях, предусмотренных федеральными законами и законами Республики Татарстан;

н) участие в пределах своей компетенции в обеспечении размещения сведений о доходах, расходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера, представленных лицами, замещающими государственные должности Республики Татарстан, в информационно-телекоммуникационной сети «Интернет», а также в обеспечении предоставления этих сведений общероссийским средствам массовой информации для опубликования;

о) проведение в пределах своей компетенции мониторинга:

деятельности по профилактике коррупционных правонарушений в органах местного самоуправления, муниципальных организациях и учреждениях, а также соблюдения в них законодательства Российской Федерации и Республики Татарстан о противодействии коррупции;

реализации организациями обязанности принимать меры по предупреждению коррупции;

п) организация в пределах своей компетенции антикоррупционного просвещения и пропаганды, а также осуществление контроля за организацией этой работы в государственных учреждениях Республики Татарстан;

р) осуществление иных функций в области противодействия коррупции в соответствии с законодательством Российской Федерации и законодательством Республики Татарстан.

## IV. Основные права Управления

6. Управление для осуществления своих задач и функций:

вносит Президенту Республики Татарстан предложения по совершенствованию антикоррупционной деятельности исполнительных органов государственной власти Республики Татарстан;

запрашивает отчеты исполнительных органов государственной власти Республики Татарстан и получает информацию органов местного самоуправления о реализации ими мер по противодействию коррупции, предусмотренных нормативными правовыми актами Российской Федерации и Республики Татарстан;

подготавливает для направления в установленном порядке в федеральные органы исполнительной власти, уполномоченные на осуществление оперативно-разыскной деятельности, в органы прокуратуры

Российской Федерации, иные федеральные государственные органы, государственные органы Республики Татарстан, территориальные органы федеральных органов исполнительной власти, органы местного самоуправления, на предприятия, в организации и общественные объединения запросы об имеющихся у них сведениях о доходах, расходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера лиц, замещающих государственные должности Республики Татарстан, государственных гражданских служащих Республики Татарстан, их супруг (супругов) и несовершеннолетних детей, о соблюдении ими запретов, ограничений и требований, установленных в целях противодействия коррупции, а также по иным вопросам в пределах своей компетенции;

проводит с гражданами и должностными лицами с их согласия беседы и получает от них пояснения по представленным сведениям о доходах, расходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера и по иным материалам;

получает в пределах своей компетенции информацию от физических и юридических лиц (с их согласия);

проводит иные мероприятия, направленные на противодействие коррупции;

использует государственные системы связи и коммуникации;

пользуется базами данных Аппарата Президента Республики Татарстан и исполнительных органов государственной власти Республики Татарстан.

## V. Взаимодействие Управления

7. Управление в пределах своей компетенции взаимодействует с Управлением Президента Российской Федерации по вопросам противодействия коррупции.

8. Управление взаимодействует с аппаратами Кабинета Министров Республики Татарстан и Государственного Совета Республики Татарстан, аппаратами Конституционного суда Республики Татарстан, Верховного суда Республики Татарстан, Арбитражного суда Республики Татарстан, Счетной палаты Республики Татарстан, органами государственной власти Республики Татарстан, органами местного самоуправления, предприятиями и организациями, а также со всеми структурными подразделениями Аппарата Президента Республики Татарстан, в том числе с:

помощниками Президента Республики Татарстан – по вопросам своевременности, полноты и объективности информирования Президента Республики Татарстан о выполнении его поручений и предоставления необходимых информационных материалов;

Управлением по работе с территориями Президента Республики Татарстан – по вопросам реализации антикоррупционной политики в муниципальных районах и городских округах Республики Татарстан, содействия Президенту Республики Татарстан в осуществлении им кадровой

политики, изучения качественного состава лиц, замещающих муниципальные должности и должности муниципальной службы, осуществления мониторинга за исполнением антикоррупционных мер, предусмотренных федеральным и республиканским законодательством;

с Департаментом государственной службы и кадров при Президенте Республики Татарстан – по вопросам обеспечения деятельности подразделений кадровых служб по профилактике коррупционных и иных правонарушений и (или) должностных лиц кадровых служб, ответственных за работу по профилактике коррупционных и иных правонарушений в государственных органах Республики Татарстан, подбора кадров, повышения квалификации и стажировки работников Управления;

с Государственно-правовым управлением Президента Республики Татарстан – по вопросам подготовки проектов законов Республики Татарстан, указов, распоряжений Президента Республики Татарстан, иных нормативных правовых актов в области противодействия коррупции;

с Департаментом Президента Республики Татарстан по вопросам внутренней политики – в части взаимодействия с общественными объединениями и Общественной палатой Республики Татарстан при реализации антикоррупционной политики, а также изучения общественного мнения о деятельности Президента Республики Татарстан, Кабинета Министров Республики Татарстан, других органов государственной власти по вопросам антикоррупционной деятельности;

с Управлением государственного протокола Президента Республики Татарстан – при организации мероприятий с участием Президента Республики Татарстан по вопросам, отнесенным к компетенции Управления;

с Управлением Президента Республики Татарстан по работе с обращениями граждан – по вопросам рассмотрения обращений граждан о реализации антикоррупционной политики, о коррупционных правонарушениях;

с Управлением документационного обеспечения и контроля Президента Республики Татарстан – по вопросам обеспечения гербовыми бланками, своевременной отправки и доставки служебной переписки Управления, исполнения поручений Президента Республики Татарстан, Руководителя Аппарата Президента Республики Татарстан;

с Управлением делами Президента Республики Татарстан – по вопросам создания необходимых условий труда для осуществления служебной деятельности работников Управления, их медицинского и социально-бытового обслуживания, внедрения новейших информационных технологий;

с Пресс-службой Президента Республики Татарстан – по вопросам освещения в средствах массовой информации деятельности Президента Республики Татарстан в области антикоррупционной политики.

9. Управление в пределах своей компетенции взаимодействует с прокуратурой Республики Татарстан, следственным управлением

Следственного комитета Российской Федерации по Республике Татарстан, Министерством внутренних дел по Республике Татарстан, территориальными органами федеральных органов исполнительной власти и иными органами государственной власти в целях реализации возложенных на Управление задач.

## VI. Ответственность

10. Работники Управления несут ответственность за выполнение возложенных на них обязанностей согласно должностным регламентам, а также в соответствии с законодательством за разглашение сведений, составляющих государственную и иную охраняемую федеральным законом тайну, сведений, ставших им известными в связи с исполнением должностных обязанностей, в том числе сведений, касающихся частной жизни граждан и должностных лиц или затрагивающих их честь и достоинство.

## VII. Организация деятельности Управления

11. Структура и штатная численность Управления утверждаются Президентом Республики Татарстан.

12. Руководство деятельностью Управления осуществляет начальник Управления, который назначается на должность и освобождается от должности Президентом Республики Татарстан.

13. Начальник Управления:

обеспечивает выполнение задач и функций, возложенных на Управление, и несет персональную ответственность за их реализацию;

участвует в совещаниях у Президента Республики Татарстан, в заседаниях Кабинета Министров Республики Татарстан, в совещаниях, проводимых республиканскими министерствами и ведомствами, а также в заседаниях органов, образуемых Президентом Республики Татарстан, при рассмотрении вопросов, отнесенных к компетенции Управления, направляет в установленном порядке для участия в работе коллегий и совещаний работников Управления;

определяет функции структурных подразделений Управления;

распределяет должностные обязанности между работниками Управления и представляет на утверждение Руководителю Аппарата Президента Республики Татарстан их должностные регламенты;

представляет Президенту Республики Татарстан подготовленные Управлением предложения и документы;

визирует проекты указов и распоряжений, иных документов, представляемых на подпись Президенту Республики Татарстан, в подготовке которых принимало участие Управление;

вносит предложения Руководителю Аппарата Президента Республики Татарстан о назначении на должность либо освобождении от должности, а также о командировании работников Управления;

в установленном порядке вносит предложения о поощрении работников Управления и применении к ним дисциплинарных взысканий.

14. На период временного отсутствия начальника Управления его обязанности исполняет заместитель начальника Управления.

15. Работники Управления назначаются на должность и освобождаются от должности Руководителем Аппарата Президента Республики Татарстан по представлению начальника Управления.

16. Информационное, документационное, материально-техническое и транспортное обеспечение деятельности Управления осуществляют Управление делами Президента Республики Татарстан и соответствующие структурные подразделения Аппарата Президента Республики Татарстан.

**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсе турында нигезләмәне раслау хакында» Указына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Президентының «Коррупциягә каршы көрәшү өлкәсендә эшчәнлекне оештыруны камилләштерү чаралары турында» 2015 елның 15 июлендәге 364 номерлы Указы басылып чыгу белән бәйле рәвештә һәм Татарстан Республикасында коррупциягә каршы көрәшү өлкәсендә эшчәнлекне оештыруны камилләштерү максатларында **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсе турында нигезләмәне раслау хакында» 2011 елның 31 гыйнварындагы ПУ-37 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2013 елның 26 июлендәге ПУ-693 номерлы, 2013 елның 3 декабрендәге ПУ-1176 номерлы һәм 2014 елның 20 августындагы ПУ-797 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Президентының «Коррупциягә каршы көрәшү өлкәсендә эшчәнлекне оештыруны камилләштерү чаралары турында» 2015 елның 15 июлендәге 364 номерлы Указы басылып чыгу белән бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты Аппараты турында нигезләмәне раслау хакында» 2006 елның 20 мартындагы ПУ-114 номерлы һәм Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты Аппараты турында» 2006 елның 5 апрелендәге ПУ-134 номерлы указлары нигезендә **карар бирәм:**»;

б) Татарстан Республикасы Президентының Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсе турында нигезләмәне кушымта итеп бирелүче яңа редакциядә бәян итәргә;

в) түбәндәге эчтәлекле $1^1$ пункты өстәргә:

«$1^1$. Татарстан Республикасы Президентының Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсенә коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча Татарстан Республикасы органы функцияләрен йөкләргә.».

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан,Кремль
2015 ел,13 октябрь
№ ПУ- 987

Татарстан Республикасы
Президентының
2015 елның «13» октябрендәге
ПУ-987 номерлы Указына
кушымта

**Татарстан Республикасы Президентының**
**Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсе турында нигезләмә**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасы Президентының Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсенең (алга таба – Идарә) хокукый хәлен, төп бурычларын һәм функцияләрен билгели.

2. Идарә Татарстан Республикасы Президенты Аппаратының коррупциягә каршы эшчәнлекне оештыру буенча Татарстан Республикасы Президенты вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тәэмин итү максатларында төзелгән структур бүлекчәсе булып тора.

Идарә Татарстан Республикасының коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча органы функцияләрен тормышка ашыра.

3. Идарә үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль конституциячел законнарга, федераль законнарга, Татарстан Республикасы Президенты указларына һәм боерыкларына, Россия Федерациясе Хөкүмәте карарларына һәм боерыкларына һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасы Конституциясенә, «Татарстан Республикасында коррупциягә каршы тору турында» 2006 елның 4 маендагы 34-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына, Татарстан Республикасының башка законнарына, Татарстан Республикасы Президенты указларына һәм боерыкларына, Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларына, үз компетенцияләре чикләрендә кабул ителгән Россия Федерациясе Президенты каршындагы Коррупциягә каршы тору Советы һәм аның президиумы карарларына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

## II. Идарәнең төп бурычлары

4. Идарәнең төп бурычлары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

а) Татарстан Республикасы Президентының коррупциягә каршы сәясәт өлкәсендәге вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тәэмин итү;

б) «Татарстан Республикасында коррупциягә каршы тору турында» 2006 елның 4 маендагы 34-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында каралган Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәтен гамәлгә ашыру буенча махсус дәүләт органы вазыйфаларын гамәлгә ашыру;

в) Татарстан Республикасы дәүләт органнарында, Татарстан Республикасы дәүләт органнары алдына куелган бурычларны хәл итү өчен оештырылган оешмаларда коррупциячел хокук бозуларны профилактикалау.

## III. Идарәнең төп функцияләре

6. Идарә түбәндәге төп функцияләрне гамәлгә ашыра:

а) аларга карата федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә башка төрле чикләүләр кертелмәгән Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның (алга таба – Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар) һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең коррупциягә каршы көрәшү максатларында кертелгән тыюлар, чикләүләр һәм таләпләрне үтәвен тәэмин итү;

б) Татарстан Республикасы дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүче затларның үз вәкаләтләрен тормышка ашырганда һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең вазыйфаи бурычларын үтәгәндә коррупциячел хокук бозуларга, шулай ук мәнфәгатьләр конфликты килеп тууга китерүче сәбәпләрне һәм шартларны ачыклау һәм аларны бетерү буенча чаралар күрү;

в) Татарстан Республикасында Коррупциягә каршы көрәшү эшен координацияләү комиссиясе эшчәнлеген тәэмин итә, комиссия утырышларына материаллар әзерли һәм аның тарафыннан кабул ителгән карарларның үтәлешен контрольдә тота;

г) үз компетенциясе чикләрендә Татарстан Республикасы Президенты Аппаратында, Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарында һәм Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарында (алга таба – җирле үзидарә органнары) оештырылган хезмәт урынында тәртипкә куелган таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтларын җайга салу буенча комиссияләр эшендә катнаша;

д) Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларга, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләргә һәм гражданнарга Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының коррупциягә каршы тору турында законнарын куллану белән бәйле мәсьәләләрдә консультация ярдәме күрсәтү;

е) Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларда, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрендә, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрдә һәм гражданнарда коррупциячел күренешләргә түзеп тормаучанлык формалаштыру;

ж) үз компетенциясе чикләрендә Татарстан Республикасы Президенты Аппаратында, Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарында аңа мәгълүм булган коррупциячел факт турында хәбәр иткән затның хокукларының һәм мәнфәгатьләренең үтәлүен тәэмин итүдә катнашу;

з) Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең нинди дә булса затларның аларны коррупциячел хокук бозуларга тарту максатында мөрәҗәгать итүнең барлык очраклары турында эшкә алучы вәкиленә, Россия Федерациясе прокуратурасы органына, башка федераль дәүләт органына, Татарстан Республикасы дәүләт органына хәбәр итү бурычын үтәвен тәэмин итү;

и) түбәндәгеләрне тикшерү:

Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан бирелгән керемнәре, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын;

Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан бирелгән керемнәре, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын;

Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның коррупциягә каршы тору максатларында урнаштырылган тыюларны, чикләүләрне һәм таләпләрне үтәвен;

к) Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләрендә һәм Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары алдына куелган бурычларны үтәү өчен оештырылган оешмаларда коррупциягә каршы тору турында Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарының үтәлешенә, шулай ук әлеге учреждениеләрдә һәм оешмаларда коррупциячел хокук бозуларны профилактикалау буенча чараларның гамәлгә ашырылуына контрольне тормышка ашыру;

л) үз компетенциясе чикләрендә коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары проектын әзерләүдә һәм карауда катнашу;

м) түбәндәге белешмәләрне анализлау:

Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы граждан тарафыннан тапшырылган керемнәре, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында;

Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә тапшырылган керемнәре, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында;

Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең коррупциягә каршы тору максатларында урнаштырылган тыюларны, чикләүләрне һәм таләпләрне үтәве турында;

Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең Татарстан Республикасы Президенты һәм Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе тарафыннан билгеләп куела торган вазыйфаларын биләгән гражданнарның, алар белән Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтеннән азат ителгәннән соң федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган очракларда хезмәт шартнамәсе һәм

(яисә) гражданлык-хокукый шартнамәсе төзелгәндә, чикләүләрне үтәүләре турында;

н) үз компетенциясе чикләрендә Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан бирелгән керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләрнең «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә урнаштыруны тәэмин итүдә, шулай ук гомумроссия массакүләм мәгълүмат чараларында бастыру өчен әлеге белешмәләрне бирүне тәэмин итүдә катнашу;

о) үз компетенциясе чикләрендә түбәндәгеләргә мониторинг уздыру:

җирле үзидарә органнарында, муниципаль оешмаларда һәм учреждениеләрдә коррупциячел хокук бозуларны профилактикалау буенча эшчәнлеккә, шулай ук аларда коррупциягә каршы тору турында Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарының үтәлешенә;

оешмаларның коррупцияне алдан кисәтү буенча чаралар күрү бурычын тормышка ашыруына;

п) үз компетенциясе чикләрендә коррупциягә каршы аңлату эшчәнлеге һәм пропаганда оештыру, шулай ук әлеге эшнең Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләрендә оештырылуына контрольне тормышка ашыру;

р) Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә коррупциягә каршы көрәшү өлкәсендә башка функцияләрне тормышка ашыру.

## IV. Идарәнең төп хокуклары

6. Идарә үзенең бурычларын һәм функцияләрен гамәлгә ашыру өчен:

Татарстан Республикасы Президентына Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының коррупциягә каршы эшчәнлеген камилләштерү буенча тәкъдимнәр кертә;

Коррупциягә каршы көрәшүнең Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган чараларын тормышка ашыру турында Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарыннан хисаплар сората һәм җирле үзидарә органнарыннан мәгълүмат ала;

билгеләнгән тәртиптә оператив-эзләнү эшчәнлеге алып барырга вәкаләтле федераль башкарма хакимият органнарына, Россия Федерациясе прокуратура органнарына, башка федераль дәүләт органнарына, Татарстан Республикасы дәүләт органнарына, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнарына, җирле үзидарә органнарына, предприятиеләргә, оешмаларга һәм иҗтимагый берләшмәләргә аларда булган Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында, коррупциягә

каршы тору максатларында урнаштырылган тыюларны, чикләүләрне һәм таләпләрне үтәве турында белешмәләр турында һәм үз компетенциясе чикләрендә башка мәсьәләләр буенча соратулар әзерли;

граждан һәм вазыйфаи затлар белән, алар ризалык биргән очракта, керемнәре, мөлкәтләре турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында бирелгән белешмәләр буенча әңгәмәләр уздыра һәм алардан аңлатмалар ала;

үз компетенциясе чикләрендә физик һәм юридик затлардан мәгълүмат ала (алар ризалык биргән очракта);

коррупциягә каршы көрәшүгә юнәлтелгән башка чаралар үткәрә;

дәүләт элемтә һәм коммуникацияләр системаларын файдалана;

Татарстан Республикасы Президенты Аппаратының һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының мәгълүматлар банкыннан файдалана.

## V. Идарәнең хезмәттәшлек итү даирәсе

7. Идарә үз компетенциясе чикләрендә Россия Федерациясе Президентының Коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча идарәсе белән хезмәттәшлек итә.

8. Идарә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы аппаратлары, Татарстан Республикасы Конституция суды, Татарстан Республикасы Югары суды, Татарстан Республикасы Арбитраж суды, Татарстан Республикасы Хисап палатасы аппаратлары, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, предприятиеләр һәм оешмалар һәм шулай ук Татарстан Республикасы Президенты Аппаратының барлык структур бүлекчәләре белән хезмәттәшлек итә, шул исәптән:

Татарстан Республикасы Президенты ярдәмчеләре белән – Татарстан Республикасы Президентына аның кушканнарын үтәү һәм кирәкле мәгълүмати материаллар бирү турында хәбәр итүнең үз вакытында, тулы һәм объектив башкарылуы мәсьәләләре буенча;

Татарстан Республикасы Президентының Территорияләр белән эшләү идарәсе белән – Татарстан Республикасы муниципаль районнарында һәм шәһәр округларында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру; кадрлар сәясәтен гамәлгә ашыруда, муниципаль вазыйфаларны һәм шулай ук муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче затларның сыйфат составын өйрәнүдә; федераль һәм республика законнарында каралган коррупциягә каршы чараларның үтәлешенә мониторингны тормышка ашыруда Татарстан Республикасы Президентына ярдәм итү мәсьәләләре буенча;

Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты белән – коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча кадрлар хезмәте бүлекчәләре яисә Татарстан Республикасы дәүләт органнарында коррупциячел һәм башка хокук бозуларны кисәтү буенча эш өчен җаваплы кадрлар хезмәте вазыйфаи

затлары эшчәнлеген тәэмин итү мәсьәләләре буенча, кадрларны сайлап алу, Идарә хезмәткәрләре квалификацияләрен күтәрү һәм стажировкаларын уздыру буенча;

Татарстан Республикасы Президентының Дәүләт-хокук идарәсе белән – Татарстан Республикасының коррупциягә каршы тору өлкәсендә Татарстан Республикасы законнары, Татарстан Республикасы Президенты указлары һәм боерыклары, башка норматив хокукый актлар проектларын әзерләү мәсьәләләрендә;

Татарстан Республикасы Президентының Эчке сәясәт мәсьәләләре идарәсе белән – Коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашырганда җәмәгать берләшмәләре һәм Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы белән үзара хезмәттәшлек итү өлешендә һәм шулай ук Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, коррупциягә каршы эшчәнлек мәсьәләләре буенча дәүләт хакимиятенең башка органнары эшчәнлеге турында җәмәгать фикерен өйрәнгәндә;

Татарстан Республикасы Президентының Дәүләт протоколы идарәсе белән – Татарстан Республикасы Президенты катнашында Идарә компетенциясенә кергән мәсьәләләр буенча чаралар оештырганда;

Татарстан Республикасы Президентының Гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү идарәсе белән – коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру турында яисә коррупциячел хокук бозулар турында гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау мәсьәләләре буенча;

Татарстан Республикасы Президентының Документлар белән тәэмин итү һәм контроль идарәсе белән – герблы бланклар белән тәэмин итү һәм Идарәнең хезмәт язышуын үз вакытында җибәрү һәм җиткерү, Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе күрсәтмәләрен үтәү мәсьәләләре буенча;

Татарстан Республикасы Президенты Эшләр идарәсе белән – Идарә хезмәткәрләренең хезмәт эшчәнлеген тормышка ашыру өчен тиешле хезмәт шартлары тудыру, аларга медицина һәм социаль-көнкүреш хезмәте күрсәтү, иң яңа мәгълүмати технологияләр кертү мәсьәләләре буенча;

Татарстан Республикасы Президентының Матбугат хезмәте белән – Татарстан Республикасы Президентының коррупциягә каршы сәясәт өлкәсендә эшчәнлеген массакүләм мәгълүмат чараларында яктырту мәсьәләләре буенча.

9. Идарә үз компетенциясе чикләрендә Татарстан Республикасы прокуратурасы, Россия Федерациясе Тикшерү комитетының Татарстан Республикасы буенча тикшерү идарәсе, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы, федераль дәүләт хакимияте органнарының территориаль органнары һәм дәүләт хакимиятенең башка органнары белән Идарәгә йөкләнгән бурычларны гамәлгә ашыру максатларында хезмәттәшлек итә.

## VI. Җаваплылык

10. Идарә хезмәткәрләре вазыйфаи регламентлар һәм шулай ук законнар нигезендә дәүләт серен һәм федераль закон белән саклана торган башка серләрне яисә аларга вазыйфаи бурычларын башкару белән бәйле рәвештә мәгълүм булган мәгълүматларны, шул исәптән гражданнарның һәм вазыйфаи затларның шәхси тормышына яисә аларның намусына һәм кешелек дәрәҗәсенә кагылышлы мәгълүматларны фаш иткән өчен җаваплы булалар.

## VII. Идарә эшчәнлеген оештыру

11. Идарәнең структурасы һәм штат саны Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан раслана.

12. Идарә эшчәнлегенә Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан вазыйфасына билгеләнүче һәм вазыйфасыннан азат ителүче Идарә башлыгы җитәкчелек итә.

13. Идарә башлыгы:

Идарәгә йөкләнгән бурычларның һәм функцияләрнең үтәлешен тәэмин итә һәм аларның тормышка ашырылуына шәхси җаваплылыкта була;

Идарә компетенциясенә кертелгән мәсьәләләрне караганда Татарстан Республикасы Президенты уздырган киңәшмәләрдә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты утырышларында, республика министрлыклары һәм ведомстволары уздыра торган киңәшмәләрдә, шулай ук Татарстан Республикасы Президенты төзегән органнар утырышларында катнаша, билгеләнгән тәртиптә коллегияләр һәм киңәшмәләр эшендә катнашу өчен Идарә хезмәткәрләрен җибәрә;

Идарәнең структур бүлекчәләре функцияләрен билгели;

Идарә хезмәткәрләре арасында вазыйфаи йөкләмәләрне бүлә һәм Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе раславына аларның вазыйфаи регламентларын тәкъдим итә;

Татарстан Республикасы Президентына Идарә әзерләгән тәкъдимнәрне һәм документларны кертә;

аларны әзерләүдә Идарә катнашкан Татарстан Республикасы Президентына кул куяр өчен бирелә торган указларның, боерыкларның һәм документларның проектларына имза сала;

Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесенә Идарә хезмәткәрләрен вазыйфага билгеләп кую һәм вазыйфасыннан азат итү, шулай ук командировкаларга җибәрү турында тәкъдимнәр кертә;

билгеләнгән тәртиптә Идарә хезмәткәрләрен бүләкләүгә яисә дисциплинар җәза бирүгә тәкъдим итә;

Идарәгә йөкләнгән бурычлар һәм функцияләрне нәтиҗәле гамәлгә ашыру өчен шәхси җаваплы була.

14. Идарә башлыгы вакытлыча булмаганда аның вазыйфаларын Идарә башлыгы урынбасары башкара.

15. Идарә хезмәткәрләре Идарә башлыгы тәкъдиме буенча Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе тарафыннан вазыйфага билгеләп куела һәм вазыйфадан азат ителә.

16. Идарә эшчәнлеген мәгълүмати, документлар, матди-техник һәм транспорт белән тәэмин итү Татарстан Республикасы Президенты Эшләр идарәсе һәм Татарстан Республикасы Президенты Аппаратының тиешле бүлекчәләре тарафыннан тормышка ашырыла.